# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге Тупач торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**30.11.2023ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач Коноваловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2.Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

- Тупач торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм салу, грейдерлау, һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

- Тупач торак пунктында зиратны тәртипкә китерү (зур агачларны кисеп алу һәм җыю, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3.Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Коновалово авыл җирлеге башлыгы урынбасары_____________ И.И.Шагиев